СОВЕТ УТЯШКИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Центральная, д.10,
с. Татарское Әдәмсә,423186

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
ӘДӘМСӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урамы, 10
Әдәмсә авылы,423186

_тел.: (8-84348) 3-47-41, факс: (8-84348) 3-47-65, Ut.Nsm@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы
Әдәмсә авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

2023 елнын «01» сентябреннен №36-133

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Әдәмсә авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 18 мартындагы 26-53 номерлы «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Әдәмсә авыл җирлегендә муниципаль норматив хокукый актлар реестрын оештыру һәм алып бару тәртибе турында» Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Әдәмсә авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, "Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында" 2009 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә "Муниципаль норматив хокукый актлар реестрларын алып бару турында" Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Советы президиумының 2016 елның 13 октябрендәге ПР-26-4 номерлы карарын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Утяшка авыл җирлеге Уставына таянып, җирле үзидарә органнары кабул иткән норматив хокукый базаны камилләштерү, унификацияләү һәм исәпкә алуны системалаштыру, аларның эшчәнлеге турында мәгълүматның ачыклыгын тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Әдәмсә авыл җирлеге Уставына нигезләнеп

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Әдәмсә авыл җирлеге советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Әдәмсә авыл җирлегендә муниципаль норматив хокукый актлар реестрларын алып бару тәртибе турында нигезләмәгә 18.03.2017 № 26-53 (Совет карарының 19.03.2020 № 64-139, 15.06.2023 №34-127) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пункт 2.4. Нигезләмәләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2.4. Реестрга муниципаль норматив хокукый актлар турында түбәндәге өстәмә

белешмәләр кертелергә тиеш:

рәсми басылып чыккан чыганак һәм дата турында; датаны күрсәтеп, хокукый экспертиза уздыру турында;

прокурор җавабы актлары турында; регистрга бару (порталда урнашу) турында.»;

1.2. Нигезләмәгә № 1, № 2, № 3, № 4 номерлы кушымталарда «Документка үзгәрешләр кертү (гамәлдән чыгару)» баганасын төшереп калдырырга.

2. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда әлеге карарны бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: http://novosheshminsk.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Әдәмсә авыл җирлеге башлыгы А.И.Назмутдинова